**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№4087**
**09.08.2019**

Башкарма комитетның 2013 елның 31 июлендәге 4542 нче карары белән расланган торак бүлмәне торак булмаган бүлмә һәм торак булмаган бүлмәне торак бүлмә итеп күчерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Торак кодексы, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ санлы Федераль закон, шәһәр Уставының 42 маддәсе, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 нче карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезнамәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2013 елның 31 июлендәге 4542 нче карары белән (Башкарма комитетның 2014 елның 11 апрелендәге 2165 нче, 2016 елның 28 июнендәге 3321 нче, 2018 елның 28 апрелендәге 2395 нче, 2018 елның 14 декабрендәге 7501 нче, 2019 елның 14 июнендәге 3044 нче карарлары редакциясендә) расланган торак бүлмәне торак булмаган бүлмә һәм торак булмаган бүлмәне торак бүлмә итеп күчерү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына, 2.5 пунктны түбәндәге эчтәлектәге 6 һәм 7 пунктчалар белән тулыландырып, үзгәрешләр кертергә:

«6) күп фатирлы йорттагы торак милекчеләре гомуми җыелышының аларның торак бүлмәне торак булмаган бүлмә итеп күчерүгә ризалыгы турында карарны үз эченә алган беркетмәсе;

7) күчерелә торган бүлмә янәшәсендәге барлык бүлмәләрнең һәр милекчесенең торак бүлмәне торак булмаган бүлмә итеп күчерүгә ризалыгы.».

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Р.Ә. Абдуллин